# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мәсгут авылы № 4 «31» октябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Мәсгут торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Якшыбай торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2025 елның 17 октябрендәге 3 номерлы карары нигезендә

**Карар кабул итте:**

1. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү, ремонтлау)

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дуслык урамындагы юлларны профильләштерү һәм вак таш түшәү);

-Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Дуслык урамындагы чишмәне төзекләндерү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru.урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Азнакай муниципаль районы Мәсгут
авыл җирлеге Башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.А. Габдрахманов